СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**« 31 » гыйнвар 2017 ел** **№ 100**

**Арча район Советының 2016 елның 12 июлендәге 64 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия составына үзгәрешләр кертү турында**

Арча муниципаль районының җирле үзидарә органнарында коррупциягә каршы көрәш өлкәсендәге эшчәнлекне камилләштерү максатларында, кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә Арча район Советы карар кылды:

1. Арча район Советының 2016 елның 12 июлендәге 64 номерлы карары белән расланган муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи тәртибе һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе(алга таба - Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Комиссия составыннан Ф.М. Абдуллинны чыгарырга;

- Гарипов Роберт Радик улы вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Арча муниципаль районы башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе»;

- Комиссия составына комиссия әгъзасы буларак Мөхәмәтова Алсу Фирдәүс кызын кертергә, аның вазыйфасын «Арча район Советы аппараты оештыру-гомуми бүлегенең юридик мәсьәләләр буенча секторы мөдире» диган редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) яисә Арча муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев